

ТАТГОСИЗДАТ 1951

ӨЧ КЫЗ



(ӘКИЯТ)

Художник
Җ. БУЛАТ
рәсемнәре

ТАТГОСИЗДАТ
ЯШЬЛӘР-БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ РЕДАКЦИЯСЕ
КАЗАН 1951



Борын-борын заманда булган икән, ди, бер хатын. Анын булган, ди, өч кызы. Бу хатын кызларымның өсте бөтен, тамак-



лары тук булсын, ди-ди, көне-төне эшләгән, ди.

Менә кызлар буйга да җиткәннәр. Алар берсеннән-берсе матур, ди, бер битләре ай, бер битләре кояш, ди, буй-сыннары

карлыгачтай сылу, ди. Өч кыз туган бер-бер артлы кияүгә чыгып, берсе артыннан берсе китеп тә барганнар.

Менә бер ел үткән, ике ел, өч ел үткән. Шулай матур гына тереклек иткәндә, әниләре авырып киткән. Күрше урманда тиен-дусты бар икән, шуны дәшеп әйткән:

— Тиен-дустым, барсана, кызларыма әйтсәнә, хәлемне белергә килсеннәрче, — дигән.

Тиен шунда ук чыгып чапкан. Тиен барып тәрәзә какканда, олы кыз җиз ләгәннәр тазартып торадыр иде, ди.

— Һай, — дип әйткән, ди, олы кыз, — бик барыр идем дә бит, аңарчы менә шушы





ләгәннәрне тазартып бетерәсем бар иде шул, — дигән ди.

Тиен моңар бик ачуланган да әйткән:

— Алайса син шушы ләгәннәреңнән мәңгегә аерылма! — дигән.

Тиеннең шулай дип әйтүе булган, ике ләгән кызны ике яктан китереп тә кысканнар. Олы кыз егылган да шунда ук гөберле бакага әверелгән.

Тиен уртанчы кызга чыгып чапкан. Уртанчы кыз бу кайгылы хәбәрне ишеткәндә, киндер суга икән. Тиенгә әйткән:






— Һай,— дигән,— әнием янына хәзер үк чыгып йөгерер идем дә бит, менә ярминкәгә киндер сугып өлгертәсем бар иде шул, — дигән.

Тиен бик ачуланган да әйткән:

— Алайса син гомерең буе киндер сугып кына тор! — дигән.

Уртанчы кыз шунда ук үрмәкүчкә әверелгән.

Тиен тәрәзәсен какканда, кече кызның камыр баскан чагы икән. Ул бер сүз дә әйтмәгән, камырлы кулларын да сөртеп тормаган, чыккан да әнисе янына йөгергән.





Тиен кече кызга әйткән:

— И сөекле бала, — дигән, — гомер буе игелек күр, кешеләрне бәхетле ит, аларга куаныч та, юаныч та бул. Кешеләр дә сине сөярләр, синең яхшылыгыңны мәңге онытмаслар, — дигән.

Кече кыз чыннан да бик рәхәт гомер кичергән, халык аны бик яраткан, ди.



ТРИ ДЕВУШКИ

(на татарском языке)

Редакторы *Г. Бәшир*

Художество редакторы *Ш. Мухаметзянов*

Техник редакторы *Х. Ракипов*

Корректоры *Р. Хәмидуллина*

Наборга бирелде 28/XII-1950 ел. Басарга кул куелды 16/X-1951 ел. ПФ 15106. Кәгазь форматы 70×92 1/16-0,38 к. т. Учет-изд. 0,53 таб. Басма табак 0,88. Табакта 49200 хәреф. Заказ № 0398.

Тираж 8000+65.

ТАССР Министрлар Советы янындагы Издательство һәм полиграфия идарәсенең Татполиграф типографиясе. Казан, Миславский ур., йорт 9.


65 тиен